РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ЯДЫГЕРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
422124, РТ, Кукморский район,
с. Ядыгерь, ул.Ленина д.28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯДЕГӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422124, РТ, Кукмара районы,
Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт

тел.: (8 84364) 35-5-88, факс (8 84364) 35-5-88; e-mail:Yad.Kuk@tatar.ru

Карар

2022 елның 24 ноябре №32

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 33 номерлы Ядегәр авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Ядегәр авыл җирлеге советы карар бирде:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 33 номерлы Ядегәр авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 29 маендагы 23 номерлы, 2015 елның 14 октябрендәге 4 номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 17 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 23 номерлы Ядегәр авыл җирлеге Советы карарлары кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 нче һәм 4 нче пунктларны өстәргә:

«3) Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендә яшәүче, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – мобилизация буенча чакырылган гражданнар) һәм аларның гаиләләре әгъзалары (ире/хатыны, балигъ булмаган балалары һәм белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча укучы 23 яшькә кадәрге балалары»);

4) мобилизация буенча чакырылган гражданнарның алар белән бергә яшәүче (яшәү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) ата-аналары.»

2. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендзге 33 номерлы Ядегәр авыл җирлеге Советы карарының 3.1 пунктындагы 3 һәм 4 нче пунктчалары нигезләмәләренең (әлеге карар редакциясендә) гамәлдә булуы 2021 елның салым чорында физик затлар мөлкәтенә салым исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитетына «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 33 номерлы Ядегәр авыл җирлеге Советы карарының 3.1 пунктның 3 һәм 4 нче пунктчаларында (әлеге карар редакциясендә) күрсәтелгән гражданнар исемлеген формалаштырырга һәм салым органына тапшырырга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүмат рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы А.Н.Фәйзуллин